ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1681**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «3 нче спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе күрсәтә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм Зеленодольск муниципаль районының 2022 елның 24 июнендәге муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (бәяләрне) билгеләү өлешендә тарифларны (бәяләрне) карап тикшерү комиссиясе карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «3 нче спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 гыйнварындагы 124 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» карарына 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Совет аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетның
2022 елның 07 июлендәге
1681 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**
**«3 нче спорт мәктәбе»**
**муниципаль бюджет учреждениесе**

**Түләүле хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм хезмәтләр исемлеге**

| **Хезмәтнең атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Бәясе, (сум.)** |
|---|---|---|
| «Яшь футболчы» физкультура-сәламәтләндерү төркеме | айга | 2 500 |
| Ябык ясалма футбол кырын (20x40) бирү | сәгатенә | 2 500 |
| Ясалма футбол кырын бирү (90x40) | сәгатенә | 4 000 |
| Ясалма футбол кырын бирү (30x18) | сәгатенә | 1 500 |